
# 21 февраль – Халыкара туган тел көне

ЮНЕСКО Генераль конференциясе тарафыннан 1999 елның ноябрендә кабул ителә

# “ Тел – рухи дөнья көзгесе”



Җиде бабамнар көйләгән
шигырь һәм дога теле,
Мөхәмmәтгариф мулла һәм
Бибимәмдүдә теле.
Юк, түгел бу читтән килгән
килмешәк – нәнкә теле,
Бу татарның җаны иңгән
әткә – әнкә теле.



***И туган тел, и матур тел,***
***Әткәм, әнкәмнең теле;***
***Дөньяда күп нәрсә белдем***
***Син, туган тел, аркылы.***

**Габдулла Тукай**



**“ Без – татарлар, телебез – татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул”**

**Каюм Насыйри**

**“ Кечкенәдән үк күңелемә урнашкан җырулар сөймәкемнән миндә туган телемезне сөю туды”**



Габдулла Тукай

**Халык сөйләмендә тел яшәсә, халык үзе яши. Халык сөйләмендә тел үлдеме, тел иясе буларак халык үзе үлә”**

К.Д.Ушинский




“ Берәү башка телне өйрәнмәкче булса, башта үз теленең грамматикасын белсен”

Каюм Насыйри




**Туган тел – иң татлы тел,**
**Туган тел – иң тәмле тел.**
**Тәмле дип, телең йотма –**
**Туган телне онытма!**


**Шәүкәт Галиев**



# Тел турында халык



Алтыда белгән ана телең-
алтмышта да онытылмас.



Тел кешенең кемлеген аңлата

Иң татлы тел- туган тел,
Анаң сөйләп торган тел.

Туган телен кадерләгән халык кадерле булыр.

***Инсафлының  теле  саф***

***Иле  барның  теле бар***

***Теленә  салынган,***
***Эшенә  абынган***

**Телең озын булса,**

**гомерең кыска була.**

**Телләр белгән -**

**илләр белгән**

Сөйдергән  дә тел,

биздергән дә  тел

Белгечләр киләсе йөзьеллыкта барлык телләрнең 95% ы яшәүдән туктар дип фараз итә. Мәсәлән, бер ел эчендә 10 тел юкка чыга диган фикер бар

# “ **Туган тел**” Роберт Миңнуллин

“И туган тел”-
Иң әйбәт шигырь!
“Туган тел” –
Иң әйбәт җыр!
“Туган тел” –
Иң әйбәт китап!
“Туган тел” –
Иң әйбәт тел!
Туган тел әйбәт булганга,
Шигыре дә, китабы да,
Җыры да иң әйбәттер!





# Сау булыгыз! Киләсе очрашуларга кадәр!

